УДК 821.512.145-2:792.09

***Р.Ф. Фәйзерахманов,***
***А.Г. Әхмәтгалиева,***
***В.Ф. Макарова***

# КӘРИМ ТИНЧУРИН ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ СӘХНӘ ЯЗМЫШЫ

В статье рассматривается история постановок пьес Карима Тинчурина на татарской сцене начиная с 1920-х годов и до наших дней. Названы режиссеры, актеры постановок, авторы музыкального сопровождения. Основанное внимание уделено выяснению причин такой популярности произведений К. Тинчурина как среди профессионального театрального сообщества, так и среди зрителей.

**Ключевые слова:** Карим Тинчурин, татарская драматургия, татарский театр, музыкальная комедия.

Татар театрын, аның тарихын, үсешен һәм репертуарын Кәрим Тинчурин исеменнән башка күз алдына да китереп булмый. Бу шәхеснең актер буларак та, режиссер һәм шул ук вакытта драматург буларак та эшчәнлеге бәяләп бетергесез. Шәкерт булып мәдрәсәдә укыган чорда – 1906 елда ук «Моназарә» исемле беренче сәхнә әсәрен язган Тинчуринның пьесалары Октябрь инкыйлабы алдыннан сәхнәгә куела башлый. Бу чорда Кәрим Тинчурин – «Сәйяр» труппасы артисты, берничә әсәр язган драматург, үз пьесаларын сәхнәгә куярга алынган режиссер булып җитлегә. Аның үз заманы татар тормышының яңарыш процессын күрсәткән, искергән тәртипләрне тәнкыйть иткән «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1910–1912), «Беренче чәчәкләр» (1913), «Назлы кияү» (1915), «Ач гашыйк» (1915), «Җилкуарлар» (1916), «Соңгы сәлам» (1917) кебек әсәрләре XX йөз башы татар әдәбиятының кыйммәтле хәзинәсен тәшкил итәләр. Беренче әсәрләре белән үк язучы драма төрен камилләштерүгә, баетуга, үзгәртүгә үзеннән зур өлеш кертә [Әдипләребез, б. 432, б. 433].

1917 елда язылган «Соңгы сәлам» драмасында Вахитны – К. Тинчурин, Олечканы – Ф. Ильская, Раузаны – Г. Болгарская, Мөхәммәтшаны – Г. Кариев, Сираҗины – Г. Мангушев уйный. Әсәрнең 1921 елда Семипалатинск татар театрында да куелуы мәгълүм [Арсланов].

Әлеге әсәрләрдән соң күп тә үтми, 1917 елның 25 августында Тинчуринның «Ятлар» драмасы да тамашачы хозурына барып ирешә.

Бу драма 1917 елның 8 сентябрендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан уйнала. Әлеге спектакльдә Хәмит ролен – Тинчурин үзе, Кыямны – Г. Кариев, Сараны – Ф. Ильская башкара. Бу драма шактый бәхетле язмышка ия була, төрле елларда, төрле театрларда кат-кат сәхнәләштерелә. Әйтик, 1920 елда Оренбургтагы

татар театры куйган спектакльдә Хәмит ролендә – Ә. Мәҗитов, Сара – Ф. Тарханова, Кыямны – М. Әпсәләмов уйнаганы билгеле. 1934 елда драманы Академия театрында режиссер Риза Ишморат сәхнәләштерә. Тик бу куелышта, заман таләп иткәнчә, пьесага байтак кына үзгәрешләр дә кертелә. Чөнки инкыйлаби карашлар да шуны таләп итә (Хәмитне – Камал III, Хәйдәрне – Г. Зыятдинов, Хәкимҗанны – З. Солтанов уйный). Шушы ук Академия театры сәхнәсендә 1959 елда режиссер Г. Йосыпов тарафыннан драма кабат яңартылып куела. Хәмит ролендә – И. Гафуров, Сараны – Г. Ибраһимова, Кыямны – Ф. Халитов, Хәкимҗанны – Г. Зыятдинов уйный.

«Назлы кияү» спектакленең дә язмышы кызыклы. Ул 1916 елда ук язылса да, инкыйлабтан соң, 1918 елның 12 гыйнварында гына дөнья күрә. Бу комедиядә К. Тинчурин зур эшләргә дәгъва итеп тә, аларны тормышка ашырырлык белеме-әзерлеге булмаган яшьләр образларын мәйданга чыгара, аларны көлке объекты ясый. Шул рәвешле, К. Тинчуринның XX йөз башы драма әсәрләре милли әдәбиятка яңа геройлар, яңа символлар алып килә. Үзләрен милләтпәрвәрләр дип санаган яшьләр тормышына багышланган «Назлы кияү» комедиясен А. Әхмәдуллин, инкыйлабка кадәрге иң яхшы комедияләрдән, дип бәяли [Ахмадуллин].

Әсәрне Кәрим Тинчурин үзе сәхнәләштерә. Габдулла Кариев белән иңгә-иң куеп эшләгән, режиссурага аннан бик күп нәрсәгә өйрәнгән Тинчуринның да эш алымнары нигездә остазыныкы кебек була. Геройларның теле, кыланмышлары тормышчан булуы белән аерылып тора. Рәшитне автор үзе, Бибине – Ф. Ильская уйный. 2014 елның 3 июнендә «Назлы кияү» комедиясе К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсенә менә. Режиссеры – Рәшит Заһидуллин. Әсәрнең темасы теләсә кайсы чор тамашачысы өчен якын һәм таныш булганга, арада еллар киртәсе тормый. Яшь, әмма буйдак Рәшитнең өйләнергә йөрү хәбәрен ишеткәч, бай кияүгә кәләш сайлап, аны башлы-күзле итәргә теләүчеләр саны шундук күбәеп китә. Һәм «яңа дусларның» мәкерле планы инде тормышка ашам дигәндә генә, бер көтелмәгән сәбәп аркасында, бар да чәлпәрәмә килә. Әлеге явыз ниятләргә каршы торучы төп көч – ул чын мәхәббәт... Әлбәттә, бүгенге заман таләп иткәнчә, комедиягә байтак үзгәрешләр кертелә, ул яңартыла, баетыла. Композитор М. Имашев, шагыйрә Г. Зәйнашева хезмәте нәтиҗәсендә, мавыктыргыч водевильгә әверелә.

Рольләрне дә егерме беренче гасыр артистлары башкара: Рәшит – Б. Зиннәтуллин, И. Байназаров; Гөлбану – З. Хәкимҗанова, Нәгыймә – Җ. Әсфәндиярова, Рамазан – З. Закиров, Гайни – Р. Сәлахова, Җиһан – Г. Гарәпшина, Шәмси – М. Нәҗмиева, Ильяс – А. Пискунов, Сабир – И. Хафизов, Зөһрә – Г. Галиуллина, Биби – К. Галиева.

Әсәрләрнең язылу, сәхнәдә куелу тәртибенә кабат әйләнеп кайтсак, 1918 елда К. Тинчурин

«Һиҗрәт» исемле хикәясен яза, шуны ук «Тутый кош» исемле комедия итеп эшли. Әсәрдә Казаннан акларны куып чыгару, инкыйлабка каршылар арасында буталыш, аларның хурлыклы рәвештә көнчыгышка качулары – «һиҗрәткә сәфәр кылу»лары сурәтләнә. Катнашучыларның азлыгы, комедиянең җыйнак күләмле булуы, заманның актуаль сорауларын чагылдыруы – әлеге спектакльне шул чорда төрле сәхнәләрдә уйнарга мөмкинлек бирә.

«Йосыф-Зөләйха» комедиясе дә революция чорын чагылдырган сатирик сәхнә әсәре буларак үзенчәлекле. Ул 1918 елда язылып, шул ук елны «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә дә куела. Булдыксыз Сәфәргалине – К. Тинчурин, бай карчык Фәизәбикәне – Н. Арапова уйный. 1961 елда Академия театрында бу спектакльне режиссер Г. Йосыпов сәхнәләштерә, Сәфәргалине – И. Гафуров. Фәизәбикәне – Ф. Камалова уйный.

«Сакла, шартламасын!» комедиясе дә 1918 елда язылган, 1919 елда сәхнәгә куелган. Шакирҗан байны – Г. Кариев, приставны – Х. Колмәмәт уйный. Бу комедия 1928 елда Әстерхан халык театрында да куела. 1958 елда исә Татар күчмә театр сәхнәсенә дә менә. Аны режиссер К. Тумашева куя. Спектакльдә С. Мөхәряпов, Г. Гыйматов, Г. Нуруллин, Ф. Фарсин кебек артистлар катнаша.

Бу әсәр бүгенге көн тамашачысы өчен дә актуаль яңгырый. Әсәрдә төп образ – бозык күңелле бай улы. Ул, үзе шикелле дуслары белән бергәләп, бер татар баен таларга план корып йөри. Егетнең максаты – байны талап акчасын алу, ә аннан әлеге җинаятьтә яшь язучы егетне гаепләп калдыру. Әмма бай малаеның уйлары тормышка ашмый кала. Тинчуринның барлык әсәрләрендәгечә, яхшылык явызлыкны җиңеп чыга. Җинаятьче үз җәзасын ала. Спектакль җиңел карала. Чөнки әлеге әсәрдә мәхәббәт тә, җыр-бию дә, юмор да – барысы да бар. 2009 елның 26 октябрендә Кәрим Тинчурин театры сәхнәсендә комедиянең премьерасы дә була, аны режиссер Р. Заһидуллин сәхнәләштерә. Рольләрне З. Харисов, А. Фәтхуллин, З. Вәлиева, И. Хафизов, Г. Гайнуллина, Р. Гайзуллин һ.б. артистлар башкара.

Бүгенге көндә дә тамашачыны җәлеп итеп торган «Казан сөлгесе» – Тинчуринның беренче музыкаль әсәре. Ул 1922 елда языла, бик күп сәхнәләрдә уйнала. Әстерхан театрында, Татар дәүләт театрында гөрләп бара, анда беренче башкаручылар арасында Б. Тарханов, Р. Кушловская, С. Айдаров кебек талантлы артистлар уйный. Спектакльгә музыканы Салих Сәйдәшев иҗат итә. 1958 елда Академия театры сәхнәсендә комедия режиссер Р. Тумашев куелышында өр-яңа сулыш ала, анда мөәзинне – К. Бариев, Г. Шамуков, Саҗидәне – В. Минкина, Мөршидәне – Р. Хәйретдинова, Ильясны – И. Гафуров уйный.

Байтак вакыт узгач, безнең чорда, төгәлрәк итеп әйткәндә, 2003 елның 4 октябрендә «Казан сөлгесе» Г. Камал исемендә-

ге татар дәүләт академия театры сәхнәсенә янә менә. Аңа кадәр бу әсәр М. Сәлимҗанов тарафыннан сәхнәләштерелгән була инде. Ф. Бикчәнтәев куелышындагы музыкаль комедия заманча төсмерләр белән баетыла. Спектакльнең асылына бераз тукталып үтү урынлы булыр. Мөәзиннең ике кызы авылда чибәрлекләре белән дан тота. Казаннан туйга килгән яшь шәкертләрнең кызларны бик күрәселәре килә. Һәм Ильяс шәкертне, көтүче итеп киендереп, мөәзин йортына озаталар. Әлбәттә инде, ике кыз да телгә оста, тапкыр бу егеткә гашыйк булалар. Яшьләрнең мәхәббәт маҗаралары турындагы бу спектакль мюзикл жанрында сәхнәләштерелгән. Сәйдәш музыкасы, заманча хореография, «тере оркестр», зәвыклы сәхнә бизәлеше тамашачыны бик тиз үз дулкынына ияртә, аның игътибарын яулый. И. Әхмәтҗанов, И. Баһманов, Н. Гәрәева, Д. Нуруллина, И. Хәйруллин, Р. Бариев, Л. Рәхимова, А. Каюмова һәм башка бик күп талантлы артистларның уены тамашаны тагын да җанландырып җибәрә.

К. Тинчуринның оста һәм сатирик теленә корылган иң яхшы пьесаларының берсе булган «Американ» 1923 елда языла, шул ук елны сәхнәдә дә куела. Ул чагында төп герой Искәндәр ролен автор үзе башкара. Әсәр М. Сәлимҗанов куелышында Г. Камал театры сәхнәсендә дә уйнала. 1993 елда әлеге спектакль режиссер Фаил Ибраһимов тарафыннан Чаллы татар дәүләт драма театры сәхнәсенә күтәрелә. Бу комедия 2009 елда Р. Заһидуллин куелышында Кәрим Тинчурин театры сәхнәсендә премьера буларак тәкъдим ителә. Тарихи кыйммәткә ия кулъязмаларга хуҗа булу өчен үзен Америка тарихчысы дип тәкъдим иткән, хәйләгә һәм ялганга оста яшь кеше образы тамашачыларны көлдереп, күңелләрен күтәрә. Рольләрне театрның әйдәп баручы артистлары Р. Гайзуллин, А. Фәтхуллин, З. Харисов, Р. Сәлахова, Р. Төхвәтуллина һәм башкалар гәүдәләндерә.

Тинчуринның иң көчле драмаларыннан саналган «Сүнгән йолдызлар» әсәренең дә язмышын бәхетле дип атарга мөмкин. Ул да 1923 елда языла, шул ук елны Татар дәүләт театрында сәхнәгә куелган. Надирны – К. Тинчурин, Исмәгыйльне – С. Айдаров, Сәрвәрне – Р. Кушловская (соңрак Г. Кайбицкая) башкара.

Мәхәббәт өчпочмагына корылган әсәр Беренче бөтендөнья сугышы, аның кеше язмышларын җимерүе хакындагы фәлсәфәгә нигезләнгән. Драматург аны төш күрү алымын кулланып тасвирлый.

Исмәгыйль өч тапкыр күргән төш – аждаһаның берәм-берәм йолдызларны сүндерүе – символик янәшәлек тудыра. Кешеләр арасындагы аңлашылмаучылык аерым берәүләр бәхетен җимерә ала, ләкин аны үз бәхетең өчен көрәшеп хәл итәргә мөмкин. Бу фикер мәхәббәт төене мисалында күрсәтелә.

Сугыш һичкемнең дә теләкомтылышын аямый: ул, гомумән, халыкны, илне бәхетсезлеккә төшерә. Сәрвәрнең, Исмәгыйльнең, Надирның үлемендә

язучы, ахыр чиктә, нәкъ менә сугышны гаепли.

Надир – татар драматургиясендә яңа, фаҗигале герой. Хәтта сугыш башлану хәбәре дә аңа мәхәббәт китерер кебек тоела. Исмәгыйль сугыштан калу өчен, колагына дару салдырып үлгәч, Сәрвәр акылыннан яза. Надир шушы хәлдәге Сәрвәр белән аралашуны бәхет саный. Биредә «ялгызлык үлемгә тиң категория итеп карала. Җәмгыятьнең кимчелекле кешеләрне кабул итмәве, читкә тибәрүе, аларның ялгыз калып усаллануы, аралашырга бөтенләй беркем булмаганда, үлемгә атлавы тормыш кануны төсен ала. Шуның белән янәшә, кешеләрнең үз бәхете өчен көрәшүен мөмкин дип санаган килеш, язучы сугыш яки язмыш кебек зуррак көчләрнең бу бәхетне җимерүен ассызыклый» [Заһидуллина, б. 181]. Әсәр геройларыннан «Надир мәхдүм кебек гаять киеренке тетрәнүләргә, көчле психологик кичерешләргә ия герой татар драматургиясендә юк иде әле. Бу, һичшиксез, Тинчуринның зур табышы, театр сәнгатенә керткән зур яңалыгы иде», – дип яза Ф. Бәширов [Бәширов, б. 11].

1998 елда бу пьесаны Чаллы татар драма театры сәхнәсендә режиссер Р. Әюпов «Йолдызлар сүнсә ни була?» дигән исем астында тамашачыга тәкъдим итә. Әсәрне романтик югарылыкка күтәрү ниятеннән, пьесага көтелмәгән ситуацияләр өстәлә, яңа һәм иске чор геройларын параллель планда уйный. Сәрвәр һәм Исмәгыйль образларын гәүдәләндерүдә режиссер үзенчәлекле алымнар куллана. Ә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә спектакль М.Сәлимҗанов тарафыннан куела [http://kamalteatr.ru/].

Бу музыкаль трагедиянең 2013 елның 12 апрелендә Кәрим Тинчурин театрында Р. Гарипова тарафыннан да яңартылып куелуына гаҗәпләнергә кирәкми. Безгә – ягъни, XXI гасырның эре шәһәрләрендә көн итүчеләр өчен – XX йөз башы татар авылы яшәешенә хас булган көндәлек тормыш, гореф-гадәтләр, җыр һәм биюләр күптән инде үткәндә калды кебек. Кичә генә гадәти булган әйберләр бүген безгә ят кебек. Ләкин, «Сүнгән йолдызлар» спектаклендә һәркем чын, әмма гадәти булмаган мәхәббәтне күрә ала. Әлеге спектакль татар халкының көнкүреше, сугыш, кайгы һәм шатлык турында. Бу куелышта Сәрвәрне – Р. Сәлахова, Исмәгыйльне – Б. Зиннәтуллин, Надирны – З. Закиров кебек яшь, талантлы артистлар уйный.

Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе студентларының музыкаль төркем булып чыгыш ясаулары спектакльне тагын да тулы канлы итә.

Драматургның шулай ук иң көчле әсәрләреннән саналырга хаклы «Җилкәнсезләр» комедиясенә тукталыйк. Ул 1926 елда Октябрьнең тугыз еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә Татар дәүләт академия театрында куела. Спектакльнең режиссеры да, төп рольне (Батырханны) уйнаучы да Тинчурин үзе була. Шулай ук З. Солтанов, Н. Сакаев, Н. Арапова, Ф. Ильская, Ш. Шамильский кебек шул чорның күренекле артистлары да сәхнә тота.

Камал театрында ул 1958 елда да куела. Сиксәненче елларда Әлмәт театрында да зур уңыш белән бара. 1960 ел ахырында Ширияздан Сарымсаков «Җилкәнсезләр»не русчага тәрҗемә итеп, В. Качалов исемендәге Казан зур драма театрында сәхнәләштерә.

Бу спектакль режиссер Р. Абдуллаев куелышында Әлмәт театры сәхнәсендә дә шактый уңышлы уйнала.

«Американ» комедиясендә драматургның комик ситуацияләр кору остасы булуын күрсәк, «Җилкәнсезләр» сәяси-сатирик комедиясе көлке белән фаҗигалелекне үреп бирүе белән үзенчәлекле.

Әсәрнең исеме инкыйлаблар алып килгән яңалыклар фонында үзләренең кыйбласын югалткан төрле катлау кешеләрен символлаштыра, аларның язмышын, көлүдән бигрәк, шәхес фаҗигасе кебек аңлау тоемлана.

Әсәрдә «җилкәнсезлек» – рухи кыйбла булмау татар югары катлавының төп сыйфаты итеп күрсәтелә. Әсәрнең кыйммәте дә заманга, андагы сәяси каршылыкларга колачлы бәя бирүе белән билгеләнә.

2016 елның 8 октябрендә «Җилкәнсезләр» кабат Камал театры сәхнәсен яулады. Әсәр бу сәхнәгә өченче мәртәбә күтәрелә, соңгысында ул тамашачыга Омск драма театры режиссеры Г. Цхвирава куелышында тәкъдим ителә. «Җилкәнсезләр» сатирик комедиясе инде күптән татар классикасы җәүһәрләре исемлегендә. Әсәр 1917 елның инкыйлабына кадәрге һәм аннан соңгы татар тормышын сурәтли. Азатлыкка, иркенлеккә омтылган татар тарихы башка милләт режиссерында да кызыксыну уята. Г. Цхвирава бу әсәрне үзе сайлый. «Спектакль татарлар өчен кызыклы, хәзерге заманда бигрәк тә. “Совет халкы” дигән милләт юк. Татар, чуваш, мари бар. Татарларга үз милли идеяләре мөһим. Тинчурин әсәрендә 1917 елны тасвирлый. Ул елда ил, дөнья, аның белән күп кенә милләтләр, шул исәптән татар милләтенең дә асты өскә килә. Пьесаны алырга дип миңа беркем дә тәкъдим итмәде. Минем Казан белән бәйләнешем бар, монда эшләгән идем, шуңа күрә татар драматургиясе белән таныш. Татар классикасы белән эшләргә теләгән идем һәм җай да чыкты. Бүгенге көндә тарихка борылып, киләчәк сорауларына җавап эзләргә кирәк», – дип сөйли «Җилкәнсезләр» режиссёры Г. Цхвирава үзенең «Азатлык» радиосына биргән интервьюсында [https://www.azatliq.org/].

1930 еллар урталарыннан К. Тинчуринның иҗат эшчәнлегендә төп урынны музыкаль драмалар били, һәм бу жанрда әдип аеруча зур уңышларга ирешә. Аның «Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1927), «Кандыр буе» (1930) исемле мелодрамалары шул чор татар театрының төп репертуарына әверелә, аннан соң да кабат-кабат уйналып, ничәмә-ничә буын тамашачыларның тирән мәхәббәтен казана.

Әсәрләрнең сюжеты катлаулы түгел. Әйтик, «Казан сөлгесе»ндә яшь шәкерт Ильясның мәхәббәт маҗаралары тас-

вирлана. «Зәңгәр шәл»дә Булат сөйгәне Мәйсәрәне ишан хәзрәт тоткынлыгыннан коткара. Бу инкыйлабка кадәрге татар җәмгыяте өчен гадәти вакыйгалар язучыга милли көнкүрешне мифлаштырырга, аны матурлык үрнәге буларак бәяләргә мөмкинлек бирә. Яшьләрнең саф мәхәббәт хисләре, милли җыр-уеннар, гадәт-йолаларны тасвирлау, аларның матур һәм самими характерда бирелеше, вакыйгалар эчендә үзара ярдәмләшү атмосферасы тудыру, яшьләрнең иске канун-кагыйдәләрне урап үтү җаен табуларын оста итеп сурәтләү әсәрләрне кызыклы һәм мавыктыргыч ясый. Ф. Бәширов фикеренчә, «халык җырларын, йолаларын, уен-биюләрен мул куллану бу әсәрләрне гомерле итә» [Бәширов, б. 11]. Д. Заһидуллина фикеренчә, шунысы да әһәмиятле: алар әдәбиятта үткәнне каралтып күрсәтү, аны тоташ караңгылыктан торган сәхифәләр рәвешендә тасвирлау тенденциясе активлашкан бер вакытта сәхнәгә чыга һәм элекке татар тормышына уңай караш тудырулары, татар романтик әдәбияты традицияләрен дәвам итүләре белән гомум әдәби барышта аерым урын тоталар [Заһидуллина, б. 182].

«Зәңгәр шәл» – Тинчурин драматургиясендә үзгә бер урын биләп торган әсәр. Ул беренче тапкыр татар театры сәхнәсенә 1926 елның 20 декабрендә күтәрелә. Әсәрне автор үзе куя, Булатны да үзе башкара. Мәйсәрәне – Р. Кушловская, ишанны – З. Солтанов уйный, шулай ук Н. Арапова, Ш. Шамильский, Х. Уразиков, Х. Сәлимҗанов кебек осталар катнаша. Шул ук чорда спектакль Мәскәү, Оренбург, Әстерхан театрларында куела. 1929 елда Академия театрында куелган вариантның режиссеры – В. Вәлиев-Сульва була, Булатны С. Айдаров башкара. Спектакльнең бу сәхнәдә өченче куелышы 1956 елда була, режиссеры – Ш. Сарымсаков. Булат белән Мәйсәрәне А. Аббасов һәм Р. Бәхтиева башкара. 1956 елда «Зәңгәр шәл» Минзәлә театрында да куела. 1970 елда М. Сәлимҗанов әлеге әсәрне Г. Камал театры сәхнәсенә яңа сулыш белән кайтара. Мәйсәрәне Ф. Хәмитова, Булатны А. Аббасов, М. Имашев (соңыннан Н. Әюпов), ишанны Ш. Биктимеров башкара. Ф. Бикчәнтәев куйган «Зәңгәр шәл» – тагын да тулы канлы булуы, яңа буын артистлар уйнавы белән үзенчәлекле. Әлеге спектакль күптән татар театрының символына һәм Камал театрының «визит карточкасына» әверелде. Тамашачыларның ташкыны кимеми, ә пьеса инде күптән легендар спектакль статусын алды.

«Зәңгәр шәл» – Г. Йосыпов режиссер булып эшләгән елларда Әлмәт театры сәхнәсендә дә уйнала.

К. Тинчуринның сәхнәдә уйналу бәхете тигән тагын берничә әсәренә тукталыйк. «Ил» драмасы 1927 елда языла, Тинчурин аны Әстерхан татар театрында эшләгән чагында үзе сәхнәгә куя. Рольләрне Х. Уразиков, Н. Арапова, Г. Булатова кебек артистлар башкара. 1929 елда драманы Академия театрында З. Солтанов куя, музыканы С. Сәйдәшев яза.

Бу спектакль Академия театрында 1932 елда яңартылып, яңа музыкага баетылып куела.

1928 елда язылган «Хикмәтле доклад» комедиясенең 1930 елда Академия театрында куелуы билгеле. Мортаза ролендә К. Тинчурин үзе уйнаган [http:// tinchurinteatr.ru/].

1940 елларда К. Тинчурин совет чынбарлыгын чагылдырган «Корыч орчык» (1930), «Кандыр буе» (1931), «Ударниклар бәйрәме» (1933), «Алар өчәү иде» (1935) кебек пьесаларын иҗат итә. Искелек һәм яңалык көрәшенә корылган әсәрләр заман алып килгән яңалыкларны, кешеләрнең аларга мөнәсәбәтен бәяләргә омтылып язылган. Әйтик, «Кандыр буе»нда егермебишмеңче коммунист Акбирдинның, «Кызыл йолдыз» колхозына рәис булып килеп, авыл кешеләре тормышын яхшыртуга юнәлтелгән эш-гамәлләре яктыртыла.

«Кандыр буе» – 1931 елда язылган, колхозлашу чорын сурәтләгән музыкаль әсәр. Аңа да көйне С.Сәйдәшев яза. Спектакль Академия театрында Тинчуринның үзе тарафыннан куела, рольләрне Х. Әбҗәлилов, С. Садыйкова, Х. Уразиков, М. Мутин, Г. Кайбицкая кебек талантлы артистлар башкара.

«Алар өчәү иде» комедиясе 1935 елда Татарстанның 15 еллыгына багышлап языла, шул ук елның язында Р. Ишморат тарафыннан Академия театры сәхнәсендә куела. Анда төп рольләрдә Ф. Ильская, Ш. Шамильский, Х. Сәлимҗанов кебек сәхнә осталары уйный. Әсәр 1935 елда Әстерхан театрында да уйнала.

Кәрим Тинчуринның әдәби мирасы бай. Драматургның XX йөз башында иҗат ителгән беренче драма әсәрләре үзгәрешләр чорындагы татар яшьләренең төрле катлау-төркемнәре тормышын, аларның рухи дөньяларын тасвирлый һәм шушы материалны символлар, укучы уйлап бетерәсе мотивларга юл күрсәтерлек ачкыч-сүзләр ярдәмендә гомумкешелек проблемалары дәрәҗәсенә куеп, зур гомумиләштерүләр ясый. Бу әсәрләр татар әдәбияты өчен яңа сурәтләү мәйданнары ача, прозада актив кулланыла башлаган эчтәлекне тирәнәйтү алымнарын драма төренә алып килә, шул рәвешле татар драмасының яңа баскычка күтәрелүен тәэмин итә. Инкыйлабтан соң, татар сәхнә әдәбияты шактый саеккан, примитивлашкан бер вакытта, драматург К. Тинчурин үз иҗатында шушы традицияләрне саклап кала, үстерә, аларны чор таләп иткән эчтәлек, халык мәзәкләре белән бәйләп бирүгә ирешә. Драматургның «Сүнгән йолдызлар», «Американ», «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл» кебек әсәрләре татар сәхнә әдәбиятының инкыйлабка кадәр ирешкән биеклеген, дәрәҗәсен саклап калуга, аны тагын да үстерүгә хезмәт итә, милли сәнгатьнең классикасына әверелә. Аларның популярлыгына тукталып, Н. Ханзафаров болай яза: «К.Тинчурин азат халык рухи халәтен заман динамикасына якын яңа сәнгатьчә алымнарда чагылдыруы белән чын новатор булды» [Ханзафаров, с. 65].

Иҗат көче әле ташып торган Кәрим Тинчурин 1937 елның

17 сентябрендә кулга алына. Халык дошманы буларак гаепләнеп, 1938 елның 15 ноябрендә атып үтерелә. 1955 елның 14 октябрендә реабилитацияләнә.

1937 елның 17 сентябрь төнендә НКВД кешеләре килеп, әдипне кулга алалар һәм Казандагы Пләтән төрмәсенә илтеп ябалар. Ел да ике ай чамасы дәвам иткән «махсус тикшерүләр» нәтиҗәсендә К. Тинчуринга җиде пункттан торган гаепләү акты игълан ителә. Ул пунктлар арасында «буржуаз милләтчеләр оешмасында әгъза булып тору», чит илдә яшәгән һәм «советның явыз дошманы» булган Гаяз Исхакый белән элемтә урнаштыру, Япония файдасына шпионлык итү кебек кеше ышанмаслык уйдырмалар да бар. Төрмәдә кыйнау, мәсхәрә ителүләрдән тәмам саулыгын югалткан әдип бу нахак гаепләрнең берсен дә танымый әлбәттә. Шуңа карамастан, 1938 елның 14 ноябрендә җыелган өч кешелек Махсус киңәшмә (ОСО) К. Тинчуринны атарга дигән хөкем карары чыгара. Шул хөкем карары нигезендә 15 ноябрь төнендә, бер сәгать илле минутта әдипнең гомере өзелә. Бу вакытта аңа нибары илле бер яшь тулган була. К. Тинчуринның китаплары китапханә фондларыннан җыеп алына, яндырыла, юк ителә. Фәкать Сталин культы фаш ителеп, илдә берникадәр хөрлек, демократик тәртипләр урнаша башлагач кына, нахакка репрессияләнгән бик күп әдәбият-сәнгать әһелләре белән беррәттән, Кәрим Тинчуринның да абруйлы исеме һәм әдәби мирасы халыкка кире кайтарыла, пьесалары яңадан театр сәхнәләрендә куела башлый [http://tataredebiyate.ru/biography/170/].

Шунысы кызык: авторның вафатыннан соң да аның кулъязмалары, сәхнәгә менәргә өлгермәгән пьесалары табыла тора һәм яңа сулыш белән яши башлый. 2016 елның 17 ноябренда Минзәлә театры сәхнәсендә К.Тинчуринның шундый әсәрләренең берсе булган «Каракүз» музыкаль драмасы күрсәтелде (пьесаның кулъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә сакланган. 2015 елда Милли китапханә Кәрим Тинчуринның ике әсәрен – «Каракүз» һәм «Нәни абый» әсәрләрен аерым китап итеп бастырып чыгара; әсәрләрнең кулъязмаларын өйрәнүче, гарәп язуыннан гамәлдәге татар язуына күчерүче, җентекле фәнни мәкалә, аңлатмалар һәм искәрмәләр белән нәшриятка әзерләүче – Милли китапханәнең гыйльми хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты, археограф һәм текстолог Раиф Мәрданов).

«Вакыйгаларның төгәл вакыты һәм урыны ачыкланмый, – ди театр директоры Р. Шәймәрданов. – Анда гади халыктан чыккан кыю биюче кызның падишаһ тарафыннан куелган җитәкчене кулга төшерүе сурәтләнә. Мондагы төп каршылык – ул вакыттагы сыйнфый көрәш». Спектакльнең режиссеры – Әтнә театрының баш режиссеры Р. Фазлыев, композиторы – Э. Галимова, баш рольне Татарстанның халык артисты Р. Муллин башкара, Каракүз ролендә – Минзәлә театры артисткасы

Д. Акматова [http://maydan.tatar/minzele-teatry-kerim-tinchurinnyn-berkajchan-da-sexneleshtermegen-pesasyn-kuya/].

Йомгак ясап әйткәндә, Кәрим Тинчуринның әдәби мирасы, бигрәк тә сәхнә әсәрләре, үзләренең гуманистик идеяэчтәлекләре, тематик киңлеге, тасвирланган чынбарлык күренешләре һәм кеше образларының тормышчанлыгы, тел-стиленең сәнгатьчә камиллеге җәһәтеннән, аларны тудырган вакыт чикләрендә генә йомылып калмыйча, заман үткән саен тагы да тирәнрәк мәгънә төсмере ала баралар һәм сәхнәдә тулы җанлы тормыш белән яшәүләрен дәвам иттерәләр.

**Әдәбият**


*Арсланов М.Г.* Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. Казан: Заман, 2014. 584 б.

*Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: истоки и формирование социалистического реализма. 1983.

Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда. 2 т. / төз. Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 735 б.

*Бәширов Ф.* Ул кабызган утлар мәңге янар // Тинчурин К. Драмалар, комедияләр, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.

*Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек/ Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. Казан: Казан ун-ты, 2011. 1 нче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты.

*Ханзафаров Н.* Драматург-новатор // Традиции и новаторство в творчестве Карима Тинчурина. Казань, 1990.

http://kamalteatr.ru/

https://www.azatliq.org/

http://tinchurinteatr.ru/

http://tataredebiyate.ru/biography/170/

http://maydan.tatar/minzele-teatry-kerim-tinchurinnyn-berkajchan-da-sexneleshtermegen-pesasyn-kuya/



***Фәйзерахманов Рашат Фәесхан улы,***
*Чаллы татар дәүләт драма театры директоры, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре*

***Әхмәтгалиева Айгөл Габдулла кызы,***
*язучы, Татарстан язучылар һәм журналистлар берлеге әгъзасы*

***Макарова Венера Фәйзи кызы,***
*филология фәннәре докторы, Чаллы дәүләт педагогия университеты профессоры*